БАВЛИНСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

12.12.2024 Баулы шәһәре № 149

Баулы шәһәр Советының 2021 елның
7 апрелендәге 27 номерлы карары белән
расланган, Татарстан Республикасы
Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре»
муниципаль берәмлеге Уставына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2024 елның 15 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Баулы шәһәр Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Баулы шәһәр Советының 2021 елның 7 апрелендәге 27 номерлы карары белән расланган, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына (Баулы шәһәр Советының 2022 елның 14 сентябрендәге 65 номерлы, 2023 елның 29 сентябрендәге 109 номерлы, 2024 елның 13 июнендәге 128 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

8 статьяның 1 пунктын 43) пунктчасы белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«43) «Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны, хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.»;

40 статьяның 1 пунктын 9.1) пунктчасы белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга:

«9.1) аның чит ил агенты статусын алуы;»;

4) пунктчаны түбәндәге абзац белән тулыландырырга:

«Шәхси ярдәмче хуҗалык турында» 2003 елның 7 июлендәге 112-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, гражданнар алып бара торган шәхси ярдәмче хуҗалыкларны, хуҗалык кенәгәләрендә исәпкә алуны гамәлгә ашыру.».

2. Уставны федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен юстиция органына җибәрергә.

3. Уставны дәүләт теркәвенә алганнан соң, мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми бастырылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Баулы шәһәре Мэры,
Шәһәр Советы рәисе И.И. Гозәеров